| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2020 Казан ш. № 510-202/кс-2020

«Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен техник суга 2021-2025 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Интеграция» «чиктәш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ЖЧҖ) өчен әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, техник суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2021-2025 елларга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ЖЧҖ өчен техник суга суга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ЖЧҖ Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына

тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.12.2020 № 510-202/кс-2020
карарына 1 нче кушымта

## 2021-2025 елларга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ өчен техник яраклы суга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр |
|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ҖЧҖ | | |
| 1.1 | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 11,04 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 11,29 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 11,29 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 11,75 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 11,75 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 12,03 |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 12,03 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 12,52 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 12,52 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 12,83 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.12.2020 № 510-202/кс-2020 карарына
2 нче кушымта

2021-2025 елларга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ЖЧЖ өчен тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Интеграция» чиктәш челтәр компаниясе» ЖЧЖ | | | | | | |
| 1.1 | Техник су | 2021 | 2 129,36 | х | - | 2,72 | - |
| | | 2022 | х | 1 | - | 2,72 | - |
| | | 2023 | х | 1 | - | 2,72 | - |
| | | 2024 | х | 1 | - | 2,72 | - |
| | | 2025 | х | 1 | - | 2,72 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге